**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия турында» 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-66 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 19 июлендәге ПУ-479 номерлы, 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы, 2010 елның 21 июлендәге ПУ-474 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-586 номерлы, 2011 елның 2 апрелендәге ПУ-181 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-626 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1234 номерлы, 2017 елның 20 июлендәге ПУ-637 номерлы, 2020 елның 27 гыйнварындагы ПУ-29 номерлы һәм 2020 елның 20 ноябрендәге ПУ-769 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.Г. Дәүлиевны, Р.К. Шәрифуллинны чыгарырга;

б) Комиссия составына Фәхриев Илназ Инсаф улын – Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасарын кертергә (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы Р.Г. Ногмановның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Таттелеком» гавами акционер җәмгыяте генераль директорының икътисадый куркынычсызлык буенча урынбасары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 28 июль
№ ПУ-511